Кvп тапкырлар кисәтvгә карамастан, тагы алдакчыларга алданганнар. Әлеге очракта Рузаевка студенты телефон мошенникларына миллион сумнан артык акча кvчергән. Россия Эчке эшләр министрлыгынын Рузаевка районы буенча тикшерv бvлеге тарафыннан Мордовия югары уку йортларынын берсенен 20 яшьлек студенткасына карата аеруча зур кvләмдә караклык факты буенча жинаять эше кузгатылган. Зыян кvрvче сойләгәнчә, якынча бер ай элек ана янәсе ул укыган югары уку йорты администрациясеннән шалтырату кергән. Әнгәмәдәш уку йорты сайтынын проблемалары турында хәбәр итә һәм кичекмәстән студентнын шәхси кабинетына керергә кинәш итә. Проблеманы хәл итv очен дәvләт хезмәтләре порталына керv паролен кертергә кирәк була, студент кыз шулай эшләгән дә. Берникадәр вакыттан сон анын белән янәсе дәvләт хезмәтләре сайты, ә сонрак Россия Үзәк банкы вәкилләре элемтәгә керә һәм анын шәхси кабинетын мошенниклар ватуы һәм акчаларын урлау омтылышы турында хәбәр итә. Аларнын кинәшләрен истә тотып, кыз ике тvләv белән «куркынычсыз счет» ка картасында саклана торган 700 000 сум кvчергән, шуннан сон тvләv чарасы финанс-кредит учреждениесе тарафыннан блокланган.
Берничә кон дәвамында студентка картаны блокировкадан тошерергә тырышып караган, ә ул моны булдыра алгач - шул ук «куркынычсыз счетка» калган акчаларын кvчергән. Зыян кvрvченен гомуми зыяны 1 108 000 сум тәшкил иткән. Тагын берничә коннән сон бу вакыйга турында ул vзенен танышына сойләгән һәм анын кинәше буенча полициягә морәжәгать иткән.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы «Куркынычсыз счетлар» булмавын искә тошерә. Әгәр сезгә билгесез кешедән шалтыратып, картада сакланган акчаларыгызны урларга маташу турында хәбәр итсә ышанмагыз, бу - мошенниклар! Шәхсән банкка морәжәгать итегез һәм проблемалар булмавына инаныгыз.